РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

11 декабрь 2018 ел Буа шәһәре № 5-36

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районының
балигъ булмаганнар эшләре
һәм аларның хокукларын яклау буенча
комиссиясе турында

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе эшчәнлеге турындагы нигезләмәне (1нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе эшчәнлеге регламентын (2нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе турында Нигезләмә турында» Буа районы Советының 2014 елның 29 декабрендәге 4-44 номерлы карары үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы
Советы рәисе М.А. Җәббаров

Буа муниципаль районы Советының
2018 елның 11 декабрендәге
5-36 номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау
буенча комиссиясе турында нигезләмә

Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турындагы кодексы, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гомумтанылган принциплар һәм халыкара хокук нормалары нигезендә, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр эшчәнлеге төзү һәм оештыру тәртипләрен, һәм аларның вәкаләтләрен билгели.

## I. Гомуми нигезләмәләр

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия даими рәвештә эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1.1. «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Буа муниципаль районында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләренең балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, караучысызлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуын кисәтү, моңа китерүче сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү, социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаганнарны социаль-педагогик тернәкләндерү, балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү очракларын ачыклау һәм моңа юл куймау буенча эшчәнлеген координацияләү.

1.2. Балигъ булмаганнар, аларның ата-аналары һәм башка затларга карата Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының администатив хокук бозулар

турындагы кодексларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау.

1.3. Комиссия юридик зат булып тормый, аның реквизитлары күрсәтелгән мөһере бар. Комиссиянең җаваплы сәркатибе комиссия атамасы язылган бланк продукциясен файдалану һәм мөһернең сакланышы өчен җаваплылык тота.

## 1.2. Комиссиянең төп бурычлары

1.2.1. Балигъ булганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләре эшчәнлеген координацияләү.

1.2.2. Балигъ булганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм торгызу, аларны барлык формадагы дискриминациядән, физик һәм психик көчләүдән, мыскыллаудан, тупас мөнәсәбәттән, сексуаль һәм башка эксплуатациядән яклау буенча чаралар күрүне тәэмин итү.

1.2.3. Социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаганнарны социаль-педагогик тернәкләндерү буенча чаралар күрүне тәэмин итү.

1.2.4. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, караучысызлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуын кисәтү, моңа этәргән сәбәп һәм шартларны ачыклау, анализлау һәм бетерү.

1.2.5. Балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү очракларын ачыклау һәм моңа чик кую буенча чаралар күрүне тәэмин итү.

1.2.6. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, караучысызлыгын кисәтү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау белән бәйле эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләренә кагылышлы төп мәсьәләләрне чишүгә килештерелгән алымнар эшләп чыгару.

1.2.7. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, караучысызлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуын кисәтү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча дәүләт теркәве узган иҗтимагый оешмалар, дини оешмалар һәм башка оешмалар һәм гражданнар белән хезмәттәшлек итү.

1.2.8. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләренең уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату, аларга оештыру-методик ярдәм күрсәтү.

1.2.9. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән башка бурычлар.

## 1.3. Комиссия эшчәнлеге түбәндәге принципларга таяна:

1.3.1. Законлылыкка.

1.3.2. Балигъ булмаганнар белән гуманлы мөнәсәтләргә.

1.3.3. Гаиләгә ярдәм итүгә һәм аның белән балигъ булмаганнарның хокукын яклау һәм законлы мәнфәгатьләрен саклау мәсьәләләрендә үзара бәйләнештә булуга.

1.3.4. Балигъ булмаганнарга алынган мәгълүматның конфиденциальлеген саклап, индивидуаль якын килүгә.

1.3.5. Балигъ булмаганнарга, аның ата-анасына яки башка законлы вәкилләренә хөрмәтле мөнәсәбәткә.

1.3.6. Балигъ булмаганнарның хокукын һәм сакланган законлы мәнфәгатьләрен бозган, балигъ булмаганнарның хокукын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча бурычларны намуссыз башкарган өчен вазифаи затларның һәм гражданнарның җавап тотуын тәэмин итүгә.

1.4. Комиссия составын оештыру тәртибе

1.4.1. Комиссияне оештыру, яңача оештыру һәм ликвидация тәртибе, аның составын раслау һәм үзгәртү Буа муниципаль районы Советы карары белән билгеләнә. Комиссиянең сан ягыннан составы балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләре санын, башкарыла торган эшнең күләмен һәм эчтәлеген исәпкә алып, тугыз кешедән азрак булмаган һәм 15 кешедән күбрәк булмаган санда билгеләнә.

1.4.2. Комиссия рәис, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип, комиссиянең башка әгъзалары составында оештырыла.

1.4.3. Авыл җирлеге территориясендә яшәүче балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм торгызу, күзәтүчесезлегенә, караучысызлыгына, хокук бозуларына һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуына этәрүче сәбәп һәм шартларны ачыклау һәм бетерү буенча оператив һәм системалы чаралар башкару максатында, авыл җирлеге Советының карары белән авыл җирлегенең Башкарама комитеты карамагында балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү буенча Советлар (алга таба – авыл җирлекләренең кисәтү буенча Советлары) оештырыла ала.

1.4.4. авыл җирлекләренең кисәтү буенча Советлары балигъ булмаганнар эшләре һәм, административ хокук бозулары турындагы эшләрне карау хокукыннан тыш, аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссия хокукларына һәм бурычларына ия.

1.4.5. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссия составына Буа муниципаль районының балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү дәүләт системасы органнары һәм учреждениеләре, шул исәптән мәгариф, опека һәм попечительлек, сәламәтлек саклау, социаль яклау, яшьләр эшләре буенча органнары, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, эчке эшләр бүлеге һәм башка кисәтү субъектлары вәкилләре керә.

1.4.6. Кагыйдә буларак, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссиянең барлык әгъзалары үз функцияләрен, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы билгеләгән очраклардан тыш, иҗтимагый башлангычта башкара.

II. Комиссинең компетенциясе

2.1. Муниципаль комиссиянең вәкаләтләре

Комиссия:

2.1.1. Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, аларның тормыш шартларын, тәрбия, укыту, хезмәт һәм ял шартларын яхшырту, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, караучысызлыгын һәм хокук бозуларын кисәтү программаларын эшләүдә катнаша һәм әлеге программаларны тормышка ашыруны контрольдә тота.

2.1.2. Җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү буенча эшнең торышы турында даими рәвештә мәгълүмат биреп тора.

2.1.3. Күзәтүчесезлек, караучысызлык, наркомания, токсикомания, алкоголизм, хокук бозулар, һәлак булулар һәм җәрәхәтләнүләр, балигъ булмаганнарның хезмәт, торак һәм башка хокукларын бозулар өлкәсендәге хәл турында мәгълүмати, аналитик һәм статистика материалларын җыю, өйрәнү һәм гомумиләштерүне, әлеге күренешләрне кисәтү буенча чаралар күрүне башкара.

2.1.4. Билгеләнгән тәртиптә оешмаларда һәм юридик зат төземичә эшмәкәрлек эшчәнлеге алып барган физик затларда балигъ булмаганнарның хезмәтен файдалану шартларын тикшерүне оештыра.

2.1.5. Балигъ булмаганнарның хокук бозуына һәм җәмгыятькә каршы гамәлләренә этәргән сәбәп һәм шартларны бетерү турында тиешле органнарга һәм учреждениеләргә тәкъдимнәр кертә, шулай ук Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы нигезендә, тиешле оешмаларга һәм тиешле вазифаи затларга административ хокук бозулар кылуга этәргән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү турында гаризалар кертәләр.

2.1.6. Балигъ булмаганнарны тәрбияләү, укыту, карап тоту шартларын үтәү буенча, шулай ук балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы учреждениеләрендә балигъ булмаганнарга мөнәсәбәтне контрольдә тотуны оештыра.

2.1.7. Тиешле органнар һәм учреждениеләр белән берлектә балигъ булмаганнарны ябык типтагы махсуслашкан укыту-тәрбия учреждениеләрендә карап тотуга бәйле мәсьәләләр буенча, шулай ук федераль законнарда каралган башка мәсьәләләр буенча судка тәкъдим ителүче материалларны әзерли.

2.1.8. Җинаять-башкарма системасы учреждениеләреннән иреккә чыккан яисә махсуслашкан укыту-тәрбия учреждениеләреннән кайткан балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыруда һәм көнкүрешен җайга салуда ярдәм итүне, мохтаҗ башка балигъ булмаганнарны урнаштыру формаларын билгеләүдә булышуны, шулай ук балигъ булмаганнарны федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган социаль реабилитация буенча башка функцияләр башкаруны тәэмин итә.

2.1.9. Балигъ булмаганнарны белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан, “Россия Федерациясендә белем бирү турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законында каралган очракларда чыгару белән бәйле мәсьәләләрне һәм укыту белән бәйле башка мәсьәләләрне карый.

2.1.10. Опека һәм попечительлек органнарына дәүләт ярдәменә мохтаҗ балигъ булмаганнарны урнаштыру һәм булышу формалары турында тәкъдимнәр кертә.

2.1.11. Балигъ булмаганнарны иҗтимагый тәрбияләүчеләр белән берлектә балигъ булмаганнарның индивидуаль программаларын һәм аларны тормышка ашыру буенча чаралар планын эшли.

2.1.12. Балигъ булмаганнар, аларның ата-аналары һәм башка законлы вәкилләре хокуклары һәм бурычлары өлкәсендә хокукый белем бирүне башкара.

2.1.13. Гражданнарның һәм оешмаларның балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, аларның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрен карый.

2.1.14. Прокуратура органнарына балигъ булмаганнарның хокуклары һәм иреге бозылуы турында хәбәр итә.

2.1.15. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, караучысызлыгын, наркомания, токсикомания, алкоголизмын, хокук бозуларын кисәтү мәсьәләләре, аларның хокукларын яклау буенча иҗтимагый оешмалар, гаммәви мәгълүмат чаралары, һөнәри берлекләр, дини һәм башка оешмалар белән үзара бәйләнештә тора.

2.1.16. Үз компетенциясендәге мәсьәләләр буенча судлар, суд приставлары хезмәте, адвокатлар коллегиясе, җәзаларны үтәү системасы органнары һәм учреждениеләре, башка хокук саклау һәм хокук яклау органнары белән үзара бәйләнештә тора.

2.1.17. Социаль-куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне ачыклый.

2.1.18. Республика комиссиясенә һәм җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү буенча эш турындагы хисапларны, шулай ук муниципаль берәмлекләрдә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, караучысызлыгын, наркомания, токсикомания, алкоголизмын, хокук бозуларын, һәлак булулар һәм җәрәхәтләнүләр, хезмәт, торак һәм башка хокукларын бозуларны кисәтү буенча чаралар турында башка мәгълүматларны әзерләп җибәрә һәм әлеге өлкәдә вәзгыятьне яхшырту буенча тәкъдимнәр кертә.

2.1.19. Судка ата-ана хокукын чикләү һәм мәхрүм итү турында шикаятьләр җибәрә.

2.1.20. Балигъ булмаганнарны, аларның таләп ителгән профессияләр алуы максатында, белем бирү учреждениеләренә юнәлдерү турында тәкъдимнәр бирә.

2.1.21. Социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаганнар һәм гаиләләр турында материалларны (делоларны) карый, балигъ булмаганнарга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) карата, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә йогынты ясау чараларын куллана.

2.1.22. Эш бирүче инициативасы буенча балигъ булмаган белән хезмәт килешүен (контракт) таркатуга рөхсәт бирә (оешма ликвидацияләнгән яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген туктаткан очраклардан тыш), кирәк булса әлеге балигъ булмаганны эшкә урнаштыру яисә аның белем бирү оешмасына керүе буенча чаралар күрәләр.

1.23. Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу турындагы шикаять һәм гаризаларны карый.

2.1.24. Федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

2.1.25. Комиссияләр инициативасы белән кузгатылган һәм балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау белән бәйле эшләрне суд караганда катнаша.

2.1.26. Балигъ булмаганнарга, аларның ата-аналарына яки законлы вәкилләренә карата, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә, йогынты ясау чараларын куллана.

2.1.27. Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозган, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча бурычларны намуссыз башкарган өчен вазифаи затларны һәм гражданнарны җавапка тарту буенча чараларны башкару.

2.1.28. Хәрби часть тәрбияләнүчесе булган ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, федераль законнарда каралган очракларда һәм тәртиптә, хәрби частьтән чыгаруны (чыгарылуын) килештерә.

2.1.29. Федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка вәкаләтләрне башкара.

## 2.2. Комиссия хокуклары

Комиссия хокуклы:

2.2.1. Билгеләнгән тәртиптә үз вәкаләтләрен башкару өчен җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан мәгълүмат соратырга һәм алырга.

2.2.2. Билгеләнгән тәртиптә балигъ булмаганнарга аларның белем алу, хезмәт, ял, сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәме, торакка хокукларын һәм башка хокукларын тормышка ашыруны тәэмин итүче оешмаларга, аларның оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына карамастан, килергә.

2.2.3. Комиссия утырышларына балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасының башка органнары һәм учреждениеләре вазифаи затларын, җирле үзидарә органнары вазифаи затларын чакырырга.

2.2.4. Билгеләнгән тәртиптә социаль куркыныч хәлдә калган балигъ булмаганнарның яшәү һәм тәрбия шартларын тикшерүне үткәрергә.

2.2.5. Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулар ачыклануы турындагы материалларны, боларга юл куйган вазифаи затларны җавапка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен тиешле органнарга юнәлдерергә.

2.2.6. Үз компетенциясе кысаларында аңлатма бирергә, язышу алып барырга һәм үзенең атамасы белән бланклары, мөһер, штампы булырга.

2.2.7. Комиссия утырышларына балигъ булмаганнарны, ата-аналарны яки законлы вәкилләрне, вазифаи затларны, оешма вәкилләрен, белгечләрне, гражданнарны чакырырга, алардан аңлатмалар, шул исәптән язмача, һәм үз

вәкаләтләрен башкару процессында барлыкка килгән сораулар буенча башка мәгълүматларны алырга.

2.2.8. Федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, муниципаль комиссия инициативасы белән кузгатылган эшләрне караганда, шулай ук балигъ булмаганнарның хокукын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау белән бәйле башка эшләрне караганда судка үз вәкилен җибәрергә.

2.2.9. Билгеләнгән тәртиптә тиешле федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына тәкъдимнәр кертергә:

тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чараларны кире кагу һәм балигъ булмаганны җинаять җаваплылыгына тарту турында;

шартлы рәвештә хөкем ителгән балигъ булмаган өчен элегрәк билгелгән бурычларны тулыландыру, тулысынча яки өлешчә бетерү турында;

шартлы рәвештә хөкем ителгән балигъ булмаганга сынау срогын озынайту турында;

суд тарафыннан билгеләнгән шартлы рәвештә хөкем итүне һәм җәзаны үтәүне кире кагу турында;

шартлы рәвештә хөкем итүне кире кагу һәм шартлы рәвештә хөкем ителгәннән хөкемен алу турында.

2.2.10. Балигъ булмаганнарның хокукына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнарына, оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына карамастан, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмаларга гаризалар кертергә.

2.2.11. Республика комиссиясе каршында балигъ булмаганнарның хокукына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләр, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, хокук бозуларын һәм башка җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү буенча чаралар күрү мәсьәләләре буенча федераль дәүләт хакимияте органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына тәкъдимнәр кертү турында, һәм тиешле тәкъдимнәрне һәм гаризаларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына кертү турында үтенеч юлларга.

2.3. Комиссия әгъзалары федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка хокукларга ия.

## III. Комиссия тарафыннан материалларны (эшләрне) карау

3.1. Комиссия материалларны (эшләрне) карый:

3.1.1. Балигъ булмаганның, аның ата-анасы яки башка законлы вәкилләре, шулай ук башка затларның гаризасы буенча.

3.1.2. Үз инициативасы буенча.

3.1.3. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләре гаризасы буенча.

3.1.4. Эш бирүчеләрнең үтенеч язуы буенча.

3.1.5. Эчке эшләр, прокуратура органнарының җинаять җаваплылыгы җиткән яшь тулганчыга кадәр иҗтимагый куркыныч гамәл кылган балигъ булмаганга карата карарлары буенча.

3.1.6. Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы һәм Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турындагы законнарында каралган тәртиптә бирелгәннәрне.

3.1.7. Гражданнар хәбәре буенча.

3.1.8. Федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка нигезләр буенча.

## 3.2. Комиссия эшчәнлеген оештыру тәртибе

Комиссия эшчәнлеген оештыру тәртибе Буа муниципаль районы Советы карары белән расланган нигезләмә буенча билгеләнә.

## 3.3. Комиссиянең карарлары, күрсәтмәләре, билгеләмәләре

3.3.1. Комиссия карарлары балигъ булмаганнарга, аларның ата-аналарына яки башка законлы вәкилләренә, башка затларга карата конкрет материалларны (эшләр) карау нәтиҗәләре буенча, шулай ук белем бирү оешмалары гаризалары, оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына бәйле булмаган рәвештә башка оешмаларның мөрәҗәгатьләрен һәм үтенечләрен карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә.

3.3.2. Комиссия күрсәтмәләре балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеге һәм хокук бозулары, шулай ук аларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга сәбәпләрне һәм шартларны юк итү максатында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына бәйле булмаган рәвештә оешмаларга кертелә.

3.3.3. Комиссиянең карарлары һәм күрсәтмәләре язмача формада булырга һәм дәлилләнгән булырга тиеш.

3.3.4. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне караганда, Комиссия Карарының эчтәлеге, шулай ук аның үз көченә керү сроклары һәм тәртипләре Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы белән билгеләнә.

3.3.5. Йогынты ясау чараларын куллану турында, балигъ булмаганны урнаштыру яисә балигъ булмаганның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда башка чаралар күрү турындагы Карарда күрсәтелә:

1) комиссиянең атамасы һәм персональ составы;

2) материалны (эшне) карау датасы һәм урыны;

3) үзенә карата материал (эш) карала торган зат турында мәгълүматлар;

4) материалны (эшне) караганда ачыкланган хәлләр;

5) каралган материаллар (эшләр) буенча комиссиянең мотивацияләнгән карары;

6) Комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән балигъ булмаганга социаль ярдәм чаралары һәм аларны күрсәтү ысуллары;

7) әлеге Карарга шикаять белдерү срокларын һәм тәртипләрен аңлату турында мәгълүматлар.

3.3.6. Комиссиянең үзенең компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча кабул

ителгән һәм үтәү өчен балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләренә җибәрелгән карарларында, ачыкланган балигъ булмаганның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулар, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлегенә, караучысызлыгына, хокук бозуларына һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуына этәрүче сәбәп һәм шартлар, аларны бетерү буенча чаралар һәм күрсәтелгән чараларны күрү сроклары күрсәтелә.

3.3.7. Комиссиянең карары һәм күрсәтмәсе Комиссия утырышында рәислек итүче тарафыннан имзалана, материалларны (эшләрне) карау тәмамлану белән үк игълан ителә, аларны кабул иткән көннән үз көченә керә.

3.3.8. Комиссиянең карары һәм күрсәтмәсе үтәү өчен тиешле дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына карамастан оешмаларга юнәлдерелә.

3.3.9. Комиссиянең карары һәм күрсәтмәсе кучерелмәсе яисә аңардан өземтә балигъ булмаганга, аның ата-анасына яки башка законлы вәкилләренә, башка кызыксынган затларга бирелә яки тиешле органнарга яки учреждениеләргә аны кабул иткәннән соң өч көн дәвамында юнәлдерелә.

3.3.10. Комиссиянең аның компетенциясе кысаларында кабул ителгән карары һәм күрсәтмәсе дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына карамастан оешмалар, шулай ук гражданнар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

3.3.11. Комиссиянең карарын яки күрсәтмәсен алганда, әлеге нигезләмәнең 3.3.10.1 һәм 3.3.10.2 өлешләрендә каралган очраклардан тыш, ул адресланган дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына карамастан оешмалар, шулай ук гражданнар, 15 көнлек срокта Карарны яки күрсәтмәне юнәлдергән комиссиягә аны үтәү буенча күрелгән чаралар турында хәбәр итәргә тиеш.

3.3.12. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләре комиссиягә әлеге нигезләмәнең 3.3.5.1 өлеше белән ярашлы рәвештә чыгарылган карарны үтәү буенча күрелгән чаралар турында әлеге карарда күрсәтелгән срокта хәбәр итәргә тиеш.

3.3.13. Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы нигезендә оешмалар һәм вазифаи затлар муниципаль комиссия чыгарган административ хокук бозуга этәргән сәбәпләр һәм шартларны бетерү турындагы күрсәтмәне аны кабул иткән көннән 30 көнлек срокта карарга һәм муниципаль комиссиягә күрелгән чаралар турында хәбәр итәргә тиеш.

3.3.14. Комиссиянең Карарын яки күрсәтмәсен үтәмәү, комиссиянең Карарында яки күрсәтмәсендә күрсәтелгән балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуны бетерү буенча чаралар күрмәү, шулай ук күрсәтелгән хокукый актларны карамыйча калдыру өчен федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгәнчә, җаваплылыкка тарту каралган.

3.3.15. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләрнең беркетмәләре комиссиянең һәр утырышында алып барыла һәм түбәндәге мәҗбүри нигезләмәләрне үз эченә ала:

комиссиянең датасы һәм урыны;

комиссия атамасы һәм составы;

карала торган материалларның (эшләрнең) эчтәлеге;

үзләренә карата материаллар (эшләр) карала торган затларның фамилиясе, исеме, атасы исеме, туу датасы һәм урыны, яшәү урыны һәм материалларны (эшләр) карау өчен әһәмиятле булган башка мәгълүматлар;

утырышта катнашучы затларның килүе турында мәгълүмат, аларның хокукларын һәм бурычларын аңлату;

утырышта катнашкан затларның аңлатмалары;

утырышта белдерелгән үтенечләрнең эчтәлеге һәм аларны карау нәтиҗәләре;

кабул ителгән карарларны игълан итү турында мәгълүматлар;

кабул ителгән карарларга шикаять бирү срокларын һәм тәртипләрен аңлату турында мәгълүматлар.

Комиссия утырышлары беркетмәләре утырышта рәислек итүче һәм сәркатип тарафыннан имзалана.

3.3.16. Комиссия билгеләмәләре Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә кабул ителә.

### 3.4. Үзенә карата материал (эш) карала торган затның хокуклары

3.4.1. Административ хокук бозу буенча үзенә карата эш алып барыла торган зат Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган хокукларга ия.

3.4.2. Комиссия тарафыннан үзенә карата материал (эш) карала торган зат түбәндәге хокукларга ия:

1) эш материалы белән танышырга;

2) аның эчтәлеге буенча искәрмәләр ясарга;

3) эшне карауда катнашырга;

4) туган телендә яисә үзе иркен сөйләшә торган телдә аңлатмалар (телдән яисә язмача) бирергә;

5) тәрҗемәче (сурдотәрҗемәче) хезмәтләреннән файдаланырга;

6) эш комиссиягә кергән вакыттан яклаучының юридик ярдәменнән файдаланырга;

7) комиссия карарына карата федераль законнарда каралган тәртиптә шикаять бирергә;

8) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка хокукларга.

### 3.5. Комиссиянең карарларына, күрсәтмәләренә карата шикаять бирү тәртибе һәм сроклары

3.5.1. Карала торган материаллар (эшләр) буенча комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларга һәм күрсәтмәләргә карата Республика комиссиясенә яисә судка шикаять бирелергә мөмкин.

3.5.2. Комиссиянең карарларына һәм күрсәтмәләренә карата Республика комиссиясенә шикаять бирү алар чыгарылган көннән алып 10 көн эчендә башкарыла. Шул срокка шикаять бирү аларның үтәлүен туктатып тора.

3.5.3. Комиссия карарларына һәм күрсәтмәләренә карата судка шикаять Россия Федерациясе граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда бирелергә мөмкин.

3.5.4. Комиссиянең административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча кабул ителгән карарларына карата шикаять Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда бирелергә мөмкин.

Буа муниципаль районы Советының
2018 елның 11 декабрендәге
5-36 номерлы карарына
2нче кушымта

Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре
һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе регламенты

Әлеге регламент Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе эшчәнлегенең эчке мәсьәләләрен, шул исәптән утырыш үткәрү, комиссия әгъзалары арасында эш бүленеше тәртибен билгели.

Әлеге регламентның таләпләре Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе эше өчен мәҗбүри булып тора.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия Буа районы Советы тарафыннан «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 143-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән.

1.2. Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе үзенең вәкаләтләрен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары карарлары, Буа муниципаль районы Уставы, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең карарлары һәм боерыклары, балигъ булганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасын тәэмин итү өлкәсендә башка норматив-хокукый актлар һәм әлеге регламент нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия даими рәвештә эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм законнарда каралган балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләренең эшчәнлеген координацияләү буенча чараларны гамәлгә ашыра.

1.4. Җирле үзидарә органнарына бирелгән балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия эшчәнлеген төзү һәм оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен финанс яктан тәэмин итү җирле бюджетка Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән субвенцияләр исәбенә башкарыла.

1.5. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең үзенең мөһере һәм чыгымнар сметасы бар. Финанслау Буа муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты аша тәэмин ителә.

1.6. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең эшчәнлегенә контроль җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турындагы тиешле Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

## 2. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия эшен оештыру

2.1. Балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссияне оештыру һәм аның составын раслау муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы тарафыннан аның вәкаләтләре срогына башкарыла. Муниципаль комиссиянең сан ягыннан составы балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләре санын, башкарыла торган эшнең күләмен һәм эчтәлеген исәпкә алып, тугыз кешедән азрак булмаган һәм 15 кешедән күбрәк булмаган санда билгеләнә.

2.2. Муниципаль комиссия рәис, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип, комиссиянең бүтән әгъзалары составында төзелә.

2.3. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия эшен оештыру балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисенә йөкләнә. Рәис комиссиянең эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, аңа йөкләнгән бурычларны башкару өчен шәхси җаваплы була, хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, муниципаль комиссия утырышларын алып бара; муниципаль комиссия кабул итә торган документларга имза сала. Рәис булмаган очракта, аның функцияләрен рәис урынбасары башкара.

2.4. Муниципаль комиссия карары буенча аның утырышларында бүтән органнарның һәм учреждениеләрнең, шулай ук балигъ булмаганнарның һәм аларның гаиләләренең проблемаларын хәл итү белән шөгыльләнүче оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең вәкилләре киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга мөмкин.

2.5. Комиссия составына даими штат нигезендә комиссиянең җаваплы сәркатибе керә.

2.6. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия әгъзалары иҗтимагый башлангычта эшли.

2.7. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия әгъзалары балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләрне караганда тигез хокукларга ия, һәм түбәндәге функцияләрне башкаралар:

муниципаль комиссия утырышында һәм аны әзерләүдә катнашалар;

алдан (муниципаль комиссия утырышына кадәр) аны карауга чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар белән танышалар;

мәсьәләне (материал, эш) карауны кичектереп тору һәм аның буенча өстәмә материаллар сорату турында тәкъдимнәр кертә;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлегенә һәм хокук бозуларына этәрүче сәбәп һәм шартлары ачыклау һәм бетерү буенча эшләрне камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертә;

карала торган мәсьәләләр (материаллар, эшләр) буенча муниципаль комиссия тарафыннан кабул ителә торган карарларны тикшерүдә катнашалар, һәм аларны кабул иткәндә тавыш бирәләр;

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзиләр;

балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу турында муниципаль комиссиягә кергән хәбәрләрне тикшерү максатларында, аларның тормышына һәм сәламәтлегенә карата янаулар булганда, көч куллану һәм балигъ булмаганнар белән рәхимсез мөгамәләнең бүтән формалары очраклары ачыкланганда, шулай ук балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга, аларның күзәтүчесезлегенә һәм хокук бозулар кылуына этәрүче сәбәп һәм шартларны ачыклау максатында, балигъ булмаганнарның белем алу, хезмәт, ял, сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәме, торакка һәм башка хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүче оешмаларга баралар;

муниципаль комиссия рәисе йөкләмәләрен үтиләр.

2.8. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия үзенед эшчәнлеген гамәлдәге законнар нигезендә алып бара. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең агымдагы эше рәис раслаган буенча алып барыла.

2.9. Җаваплы сәркатип балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләрне карауга тиешле әзерлек үткәрә.

2.10. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең кадрлары белән эшне рәис башкара. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең рәисе балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисенең урынбасары, җаваплы сәркатип һәм әгъзаларының квалификациясен күтәрү буенча эшне оештыра.

2.11. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиядә килгән кешеләрне кабул итү башкарыла. Кабул итү тәртибе һәм вакыты балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Кабул иткән вакытта кергән гариза һәм шикаятьләр законнарда билгеләнгән срокларда карала.

2.12. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең эшчәнлеген яхшырту максатында суд практикасын даими рәвештә гомумиләштерүләр үткәрелә. Суд практикасын даими рәвештә гомумиләштерүләр нәтиҗәләрен исәпкә алып, законнарны предметлы өйрәнү буенча, хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү буенча эш оештырыла.

2.13. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиядә билгеләнгән формада статистика хисабы алып барыла. Статистика мәгълүматлары квартал саен Республика балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе раслаган форма буенча тәкъдим ителә. Әлеге хисапларның нигезен административ хокук бозулар турында беренчел исәп, гаризалар һәм шикаятьләр тәшкил итә.

Статистика хисабын дөрес һәм үз вакытында тәкъдим итү җаваплылыгы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисенә, ул булмаганда – урынбасарга һәм җаваплы сәркатипкә йөкләнә.

2.14. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карар чыгарылганчы, законнарда каралган очраклардан тыш, кемгә дә булса бирү тыела.

2.15. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиядә мәгълүмати-белешмә эше алып барыла.

## 3. Утырышны алып бару тәртибе

3.1. Эшләр, «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, җаваплы сәркатип һәм комиссия әгъзалары, эштә катнашкан башка затлар һәм аларның вәкилләре составындагы утырышта карала.

3.2. Утырышта муниципаль комиссиянең рәисе яисә аның урынбасары, шулай ук балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең җаваплы сәркатибе катнашуы мәҗбүри булып тора.

3.3. Кагыйдә буларак, комиссия утырышлары ачык була һәм ачыктан-ачык алып барыла. Анда, әгәр бу балигъ булмаганның мәнфәгатьләренә каршы килмәсә, гаммәви мәгълүмат чаралары вәкилләре килә ала.

3.4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышлары законнар таләпләрен үтәп, утырышлар залында уздырыла, әгәр ул булмаса эшләрне башка бүлмәдә карарга рөхсәт ителә.

3.5. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышлары, әгәр анда аның әгъзалар яртысыннан азрак булмаган санда катнашса, хокуклы булып исәпләнә. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия әгъзалары аның утырышларында алмаштырылу хокуксыз катнаша.

3.6. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышлары вакытында вино-, видео- һәм фото төшерү балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе рөхсәте белән, әгәр бу балигъ булмаганның мәнфәгатьләренә каршы килмәсә, башкарыла.

3.7. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карары белән утырышлар ябык була ала. Аларда балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия әгъзалары, хокук саклау органнары һәм махсус чакырылган затлар гына катнашырга хокуклы.

3.8. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышына әзерлекне җаваплы сәркатип башкара, ул каралырга билгеләнгән эшләр исемлеген төзи, рәислек итүчегә эшне карау мөмкинлеге турында хәбәр итә, якларның килүен һәм вәкилләрнең вәкаләтләрен, шулай ук өстәмә материалларның керүен тикшерә.

3.9. Административ хокук бозу турындагы эшне тикшерү өчен билгеләнгән вакытта рәислек итүче комиссия утырышын ача, комиссия составын игълан итә, эштә катнашучыга хокукларын һәм бурычларын аңлата, утырышны алып бару тәртибен билгели, административ процесста катнашучыларның гаризалары, үтенечләре барлыгын ачыклый, эшнең барлык шартлары тулы һәм һәрьяклап ачыклануына этәреп, утырыш белән җитәкчелек итә, утырышта тиешле тәртипне тәэмин итә.

3.10. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия каравына кертелгән мәсьәләләр буенча материаллар суд практикасын күзәтү (гомумләштерү) рәвешендә тәкъдим ителә.

3.11. Административ җаваплылыкка тарту турында мәсьәләләрне һәм беркетмәләрне карау чираты белдерү кәгазе белән билгеләнә. Кирәк булганда балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия бу чиратны үзгәртергә хокуклы.

3.12. Беркетмәне карау рәислек итүченең административ материал шартлары турындагы докладыннан башлана. Доклад тәмамланганнан соң балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия әгъзалары каралган эшнең төп мәсьәләләре буенча сораулар бирергә хокуклы.

3.13. Әгәр комиссия утырышына карала торган административ эш буенча чакырылган яклар вәкилләре килсә, рәис, рәис урынбасары, әгъзалар аларга сораулар бирергә хокуклы.

3.14. Административ эш буенча докладтан соң комиссия беркетмә буенча фикер алышуга күчә, анда комиссия әгъзалары гына катнаша.

3.15. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карары балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рәисе белән имзалана.

3.16. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең һәр утырышында беркетмә алып бару мәҗбүри, аны җаваплы сәркатип башкара.

3.17. Эшне карауны кичектерү, тәнәфес игълан итү һәм яңадан башлап җибәрү гамәлдәге законнар таләпләрен үтәп башкарыла.

3.18. Эшне төп билгесе буенча карау тәмамланганнан соң балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карар чыгару өчен тәнәфес игълан итә, бу хакта рәислек итүче утырыш залында булганнарга игълан итә.

3.19. Беркетмә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышы тәмамланганнан соң өч көннән дә соңармыйча әзерләнергә һәм имзаланырга тиеш.

3.20. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карарлары, аларны тарату балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия әгъзалары тарафыннан башкарыла.

3.21. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең рәислек итүчесе комиссия үткәрү барышында кабул иткән күрсәтмәләр һәм карарлар үтәлешен контрольдә тотуны җаваплы сәркатип башкара.

## 4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карары турында

4.1. Комиссия карарлары карар формасын чыгарыла.

Карар утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Комиссия карары язмача рәвештә булырга һәм дәлилләнгән булырга тиеш.

Карар рәислек итүче, сәркатип һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм комиссия утырышында яңгыратыла.

Комиссиянең балигъ булмаганга, аның ата-анасына (законлы вәкилләренә) җәза белдерү турындагы карары бер ел дәвамында гамәлдә була һәм комиссия тарафыннан вакытыннан алда кире кагыла ала.

4.2. Бер үк вакытта утырышта катнашкан затларга, һәм аларның вәкилләренә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карарына шикаять белдерү тәртипләре аңлатыла.

4.3. Карар күчерелмәсе өч көн дәвамында, ул кемгә карата чыгарылган булса, шул затка тапшырылырга яки җибәрелергә тиеш.

Карарның күчерелмәсе имза куйдырып тапшырыла. Әгәр карар күчерелмәсе җибәрелсә, эштә тиешле язу языла.

4.4. Законлы көченә кергән балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карарын үтәү федераль законнарга ярашлы рәвештә башкарыла.

4.5. Карарны үз вакытында бирүне һәм карарның күчерелмәләрен таратуны контрольдә тоту балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең җаваплы сәркатибенә йөкләнә.

4.6. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карарына шикаятьләр яисә ризасызлык белдерүләр Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексында билгеләнгән тәртиптә карала.

## 5. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия карарын үтәү

5.1. Комиссиянең үз компетенциясе кысаларында кабул ителгән карарлары һәм күрсәтмәләрен дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына карамастан оешмалар һәм шулай ук гражданнар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

5.2. Комиссиянең карарын яки күрсәтмәсен алгач, әлеге регламентның 5.3 һәм 5.4 пунктларында каралган очраклардан тыш, ул адресланган дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый формаларына һәм

милекчелек формаларына карамастан оешмалар һәм шулай ук гражданнар 15 көнлек срокта карар яки күрсәтмә юнәлдергән комиссиягә аны үтәү буенча күрелгән чаралар турында хәбәр итәргә тиеш.

5.3. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү системасы органнары һәм учреждениеләре Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясе турында нигезләмәнең 3.3.6 өлешенә ярашлы рәвештә чыгарылган карарны үтәү буенча күрелгән чаралар турында комиссиягә әлеге карарда күрсәтелгән срокта хәбәр итәргә тиеш.

5.4. Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы нигезендә комиссиянең административ хокук бозуларга этәрүче сәбәп һәм шартларны бетерү турында керткән күрсәтмәсен оешмалар һәм вазифаи затлар аны алганнан соң 30 көнлек срокта карарга һәм комиссиягә күрелгән чаралар турында хәбәр итәргә тиеш.

5.5. Комиссиянең карарын яки күрсәтмәсен үтәмәү, комиссиянең карарында яки күрсәтмәсендә күрсәтелгән балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуны бетерү буенча чаралар күрмәү, шулай ук күрсәтелгән хокук актларын карамыйча калдыру федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән җаваплылыкка тартыла.

5.6. Комиссия билгеләмәләре Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы белән каралган очракларда һәм тәртиптә кабул ителә.

5.7. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиянең, аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карары аның законлы көченә кергән вакытыннан үтәлергә тиеш.

5.8. Административ штраф административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан, әлеге карарның 5.9 пунктында каралган очраклардан тыш, административ штраф салу турындагы карар законлы көченә кергән көннән, яисә гамәлдәге Кодексның 31.5 статьясында каралган кичектереп тору срогы яки соңрак түләү срогы тәмамланган көннән алты көннән соңармыйча түләнергә тиеш.

5.9. Чит ил гражданинына яки гражданлыгы булмаган затка Россия Федерациясе чикләреннән административ чыгарып җибәрү белән беррәттән билгеләнгән административ штраф, административ хокук бозу турындагы эш буенча тиешле карар законлы көченә кергән көннең икенче көнендә түләнергә тиеш.

5.10. Административ штраф суммасы административ җаваплылыкка тартылган зат тарафыннан банкка яки башка кредит оешмасына кертелә яки күчерелә.

5.11. Комиссиянең каралган материаллар (эшләр) буенча кабул ителгән карарларына һәм күрсәтмәләренә карата шикаятьне Республика комиссиясенә яки судка белдерергә була.

5.12. Комиссиянең каралган материаллар (эшләр) буенча кабул ителгән карарларына һәм күрсәтмәләренә карата шикаять Республика комиссиясенә алар чыгарылган көннән 10 көнлек срок эчендә белдерелә. Күрсәтелгән срокта шикаять бирү аларны үтәүне туктатып тора.

5.13. Комиссиянең карарларына һәм күрсәтмәләренә шикаятьне судка Россия Федерациясенең гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм срокта бирергә була.

5.14. Комиссиянең административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча кабул ителгән карарларына шикаятьне Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексы белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда бирергә була.

5.15. Әлеге регламентның 5.8 һәм 5.9 өлешләрендә күрсәтелгән срок тәмамлануга административ штраф түләнүе турында таныклык бирүче документ, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмати системасында административ штраф түләнүе турында мәгълүмат булмаса, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия ун тәүлек дәвамында, ә әлеге регламентның 5.9 өлешендә каралган очракта бер тәүлек дәвамында, федераль законнарда каралган тәртиптә үтәтү өчен административ штраф салынуы турында карарны аның түләнмәве хакында тамга куеп, башкаручы-приставка юнәлдерә.

5.16. Штраф салу рәвешендәге административ җәза гаепле затларны кылган хокук бозуларны бетерү зарурлыгыннан азат итми.